СОВЕТ
БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ УРСАК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«18» сентябрь 2025 ел Олы Урсак авылы № 2

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
«Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Башлыгын сайлау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Урсак авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 42 статьясы,яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе утырышының 3 нче номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Башлыгы, Олы Урсак авыл җирлеге Советы Рәисе итеп 3 нче Ленин бермандатлы сайлау округыннан депутат Нуреев Рамил Хәлим улын сайларга.

2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Олы Урсак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясының 5 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп Нуреев Рамил Хәлим улын билгеләргә.

3 . Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында һәм «Кайбыч таңнары»-«Кайбицкие зори» газетасында бастырып чыгарырга, http://brusakov-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге Советы
утырышында рәислек итүче Салахов А.Ш.